**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ГЛАВА ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

422720, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Дубъязы, ул. Ленина, 28

Тел./факс: +7(84365) 61-2-86, 61-2-97 e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**22 нче ноябрь 2021 е.** **№ 3**

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Дөбъяз авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 24 октябрендәге 138 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Дөбъяз торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 04 декабрендә 14.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча: Дөбъяз ав., Ленин ур., 28. (Дөбъяз авыл клубы янында) билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Дөбъяз торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 05 декабрендә 14.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча: Дөбъяз ав., Ленин ур., 28. (Дөбъяз авыл клубы янында) билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Дөбъяз торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2021 елның 06 декабрендә 14.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча: Дөбъяз ав., Ленин ур., 28. (Дөбъяз авыл клубы янында) билгеләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Дөбъяз торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым

кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Авдеев урамында юлны вакт аш белән түшәүгә
- Дөбъяз авылы эчендәге асфальт юлларны ямауга

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Галиуллин